БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 5 » декабрь 2018 ел № 355

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларының 2019 елга норматив чыгымнарын раслау турында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273 номерлы Россия Федерациясе Законының 99 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясындагы 1 өлешенең 11 пункты, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларын норматив финанслауны кертү турында» 2007 елның 12 декабрендәге 543 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. 2019 елга кушымта итеп бирелгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карауга норматив чыгымнарны.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы финанс-бюджет палатасы тарафыннан түбәндәгеләр белән расланган белем бирү оешмаларының норматив чыгымнары нигезендә белем бирү оешмаларын финанслауны тәэмин итәргә:

«2019 елга Татарстан Республикасында гомуми белем бирү оешмаларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем, шулай ук өстәмә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруны дәүләт гарантияләрен финанс белән тәэмин итү нормативларын раслау турында» 2018 елның 24 сентябрендәге 57-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы белән;

әлеге карарның 1 пункты белән.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2019 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы И.С. Галимуллин

Расланган
Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2018 елның 5 декабрендәге
355 номерлы карарына
1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары каршындагы интернатларда һәм гомуми белем бирү интернат-мәктәпләрендә тәрбияләнүчеләрне карауга**
**НОРМАТИВ ЧЫГЫМНАР**

| Гомуми белем бирү оешмасы тибы һәм төре | Территориаль урнашу | Бер тәрбияләнүчегә норматив чыгымнар, елга сумнарда |
|---|---|---|
| Гомуми белем бирү оешмасы каршындагы интернат | шәһәр җирлеге | 89268 |
| | авыл җирлеге | 90630 |
| Гомуми белем бирә торган мәктәп-интернат | шәһәр җирлеге | 135418 |
| | авыл җирлеге | 139893 |